**СОВЕТ ГОРОДА МАМАДЫШ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. М. Джалиля, 23/33, г. Мамадыш, 422190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАМАДЫШ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**
М.Җәлил ур., 23/33, Мамадыш ш., 422190

тел.:(85563) 3-15-90, факс 3-24-00 ; e-mail:gorsovet.mamadysh@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 6-18** **от «15» декабря 2023г**

**«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында карар проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы турында» 2018 елның 20 августындагы 4-25 номерлы Мамадыш шәһәре Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:
1.1. 5 статьяның 1 өлешендәге 29 пунктында "торак пункт территориясендә дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук" сүзләрен төшереп калдырырга (01.09.2024 елдан үз көченә керә);

1.2. Уставның 5 статьяның 1 өлешендәге 31 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"31) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру ";

1.3.Уставның 77 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«77статья . Муниципаль хокукый актларның үз көченә керүе һәм игълан ителүе

1. Җирлек Советы карарлары, әгәр карарда башкасы билгеләнмәсә, җирлек башлыгы тарафыннан имзаланганнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Җирлек советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексына ярашлы рәвештә үз көченә керә.

Җирлек Советының Уставын кабул итү яки әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карарлары Федераль законнар, әлеге Устав белән билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

2. Җирлек башлыгының, җирлек башкарма комитеты җитәкчесенең, җирле үзидарәнең башка вазифаи затларының хокукый актлары, әгәр актлар белән башкасы билгеләнмәгән булса, алар имзаланган көннән үз көченә керә.

3. Муниципаль хокукый актлар муниципаль берәмлек уставында билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә, Россия Федерациясе Салым кодексына ярашлы рәвештә үз көченә керә торган салымнар һәм җыемнар турында җирле үзидарә вәкиллекле органнарының норматив хокукый актларыннан тыш.

4. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, муниципаль берәмлек оештыручы булып торган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

5. Муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләрне игълан итү тәртибе муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә һәм алар белән гражданнарны таныштыру мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш, муниципаль хокукый актлардан яисә федераль закон белән чикләнгән мәгълүматлар булган аерым нигезләмәләрдән тыш.

6. Муниципаль хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән Килешүне игълан итү дип түбәндәгеләр танылa:

1) муниципаль хокукый актны рәсми рәвештә бастырып чыгару;

2) муниципаль хокукый актны чикләнмәгән затлар өчен (дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль китапханәләр, башка урыннарда)ачык булган урыннарда урнаштыру;

3) муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру;

4) муниципаль берәмлек уставында каралган гражданнарны муниципаль хокукый акт, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешү белән таныштыру мөмкинлеген тәэмин итүнең башка ысулы.

7. Муниципаль хокукый актның, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең рәсми басмасы булып аның тулы текстының тиешле муниципаль берәмлектә таратылган вакытлы басмада беренче басылуы яки аның тулы текстының интернет челтәрендә беренче урнаштырылган тексты санала.

8. Муниципаль хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми бастырып чыгару “Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында” 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль берәмлектә “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә аларны чикләнмәгән затлар даирәсе файдалана алырлык урыннарда (дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль китапханәләр биналарында,

урыннарда йөрү мөмкинлеге булган башка урыннарда) бер яисә берничә тоташу пункты булдыру тәэмин ителә.

9. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле сайтның доменный исемен һәм муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне рәсми бастырып чыгару гамәлгә ашырыла торган массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында белешмәләрне күрсәтеп, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге вакытлы матбугат басмасы һәм (яисә) челтәр басмасы атамасы муниципаль берәмлек уставында күрсәтелә.

10. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның доменнарын һәм муниципаль хокукый актларны халыкка игълан итү (рәсми бастырып чыгарылудан тыш) гамәлгә ашырыла торган массакүләм мәгълүмат чаралары буларак аларны теркәү турында белешмәләрне, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне күрсәтеп, вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге муниципаль берәмлек башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән гомуми игътибарга җиткерелә.

11. Муниципаль норматив хокукый актлар, шул исәптән җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән хокукый актлар рәвешендә рәсмиләштерелгән, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш, аны оештыру һәм алып бару Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.»

2.Түбәндәгеләрне расларга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы турында» 2018 елның 20 августындагы 4-25 номерлы Мамадыш шәһәре Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе 1 нче кушымта нигезендә;

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы турында» 2018 елның 20 августындагы 4-25 номерлы Мамадыш шәһәре Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе 2 нче кушымта нигезендә.

3. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы турында» 2018 елның 20 августындагы 4-25 номерлы Мамадыш шәһәре Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем (алга таба - эшче төркем) төзергә:

Иванов Анатолий Петрович - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре башлыгы, эшче төркем рәисе;

Захаров Владислав Александрович –Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре башлыгы ярдәмчесе, эшче төркем әгъзасы;

Галеева Венера Ибраһим кызы - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре бухгалтеры, эшче төркем әгъзасы.

4. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы турында» 2018 елның 20 августындагы 4-25

номерлы Мамадыш шәһәре Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны 2024 елның _______________ 09.00 сәг.; 422190, Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, М.Җәлил ур.; 23/33 йорт адресы буенча дип билгеләргә.

5. Мамадыш шәһәре башкарма комитетына «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы турында» 2018 елның 20 августындагы 4-25 номерлы Мамадыш шәһәре Советы карарына гавами тыңлауларда әйтелгән һәм аның барышында фикер алышкан тәкъдимнәрне исәпкә алып, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертеп, проект буенча эшләп бетерергә, һәм, икенче укылышта кабул итү өчен, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре Советына кертүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәренең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре башлыгы ярдәмчесе В.А.Захаровка йөкләргә.

Шәһәр башлыгы,
Мамадыш муниципаль районы
Мамадыш шәһәре Советы рәисе А.П. Иванов

Мамадыш муниципаль районы
Мамадыш шәһәре Советының
___________. 2023 ел. № ______
карарына 1 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы турында» 2018 елның 20 августындагы 4-25 номерлы Мамадыш шәһәре Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе»

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы турында» 2018 елның 20 августындагы 4-25 номерлы Мамадыш шәһәре Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәре 422190, Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, М.Җәлил ур.; 23/33 йорт адресы буенча Мамадыш шәһәре Советына 101 каб. кертелә, 3-24-00 телефоны буенча факс аша, шулай ук Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре Советына Gorod.Mam@tatar.ru электрон почта аша , фамилия, исем, әтисенең исеме, туган елын , яшәү адресын күрсәтеп , түбәндәге төзәтмәләр таблицасы формасында җибәрелә :

| № | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмәләр тексты | Төзәтмәне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмәләр авторы (Ф.И.А и., адрес, Эш яки уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә әлеге карарны халыкка җиткергән көннән 8 дән 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Гавами тыңлауларда катнашу хокукы белән катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: 422190, Республика Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, М.Җәлил ур, 23/33 йорт, №101 кабинет шәхсән яки почта аша, лично или по почте (Конвертта «Обсуждение Устава» или «Публичные слушания» дигән тамга белән), факс аша: 3-24-00, шулай ук Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре Советына Gorod.Mam@tatar.ru электрон почта аша.

Заявкалар эш көннәрендә гавами тыңлаулар уздыру датасына кадәр 8 сәгатьтән 16 сәгатькә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре эш төркеме тарафыннан теркәлә һәм Советны һәм шәһәр башлыгын карау өчен тапшырыла.

Мамадыш муниципаль районы
Мамадыш шәһәре Советының
____________. 2023 ел. № _______
карарына 2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы турында» 2018 елның 20 августындагы 4-25 номерлы Мамадыш шәһәре Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе

(Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль берәмлек уставы һәм гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә)

1. «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы турында» 2018 елның 20 августындагы 4-25 номерлы Мамадыш шәһәре Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар (алга таба - гавами тыңлаулар) Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уставының 19 статьясы нигезендә уздырыла.
2. Үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен гавами тыңлауларда катнашучылар булып гавами тыңлаулар уздыру датасына кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча язма гариза биргән затлар тора.
3. Гавами тыңлауларда катнашу хокукына ия һәркем катнашырга мөмкин.
4. Катнашучыларны теркәү гавами тыңлаулар башланганчы 1 сәгать алдан башлана.
5. Тыңлауларда җирлек башлыгы, җирлек башкарма комитеты җитәкчесе, Җирлек башлыгы урынбасары, җирлек башлыгы вәкаләтле башка затлар рәислек итә ала.
6. Гавами тыңлаулары рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул катнашучыларга фикер алышу мәсьәләсенең асылы, тыңлаулар үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.
7. Беркетмәне рәсмиләштерү, килгән тәкъдимнәрне, тәкъдимнәрне исәпкә алу өчен рәислек итүче тәкъдиме буенча ачык тыңлаулар секретариаты сайлана.
8. Чыгышлар эзлеклелеге һәм вакыты каралган мәсьәләнең эчтәлеген, гавами тыңлауларында катнашу өчен килгән язма гаризалар санын һәм башка мәсьәләләрне исәпкә алып, гавами тыңлауларын үткәрү регламенты белән билгеләнә. Рәис рөхсәте белән чыгыш ясау вакыты озайтылырга мөмкин.
9. Гавами тыңлауларында катнашучылар чыгыш тәмамланганнан соң чыгыш ясаучыларга сораулар бирергә хокуклы.

10. Гавами тыңлауларын үткәргәндә тәртип саклау гавами тыңлауларында катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора. Гавами тыңлауларында катнашучылар гавами тыңлаулары барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.
11. Гавами тыңлауларында катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә бирелә һәм гавами тыңлаулары беркетмәсенә теркәлә.
12. Гавами тыңлаулар беркетмәсенә рәислек итүче имза куя һәм ул жирлек Советы материалларында саклана.